РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**03.11.2022** Кукмара ш. **№ 381**

Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләренә социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында

«Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында» 1997 елның 26 февралендәге 31-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә **карар бирәм:**

1. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) (алга таба – гаиләләргә) түбәндәге ярдәм чараларын билгеләргә:

Кукмара муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларына чираттан тыш кабул итү хокукы бирү;

Кукмара муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүдән азат итү;

Кукмара муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмаларында 1 – 11 сыйныфта укучыларга бушлай кайнар ризык бирү;

Кукмара муниципаль районының өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениеләрендә гамәлгә ашырыла торган өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча шөгыльләргә (түгәрәкләргә, секцияләргә һәм башка шундый шөгыльләргә) йөргән өчен түләүдән азат итү.

2. Кукмара муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарда каралган ярдәм чараларын бирү Россия Федерациясе гражданнарының Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә мобилизация буенча хәрби хезмәт үтүе чорында гамәлгә ашырыла.

4. Әлеге карар 2022 елның 21 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (http://kukmor.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.Х. Гарифуллин**